КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2022 ел, 7 март г.Казань № 205

2022 елда яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы, амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтелүче пациентларны дәвалау өчен дару препаратлары сатып алу чараларын финанслар белән тәэмин иткәндә барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган максатчан билгеләнешкә ия башка бюджетара трансферттан файдалану тәртибен раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2022 елда яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы, амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтелүче пациентларны дәвалау өчен дару препаратлары сатып алу чараларын финанслар белән тәэмин иткәндә барлыкка килә торган Россия Федерациясе субъектларының һәм Байконур шәһәренең чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан финанслар белән тәэмин итү чыганагы булып Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондының бюджет ассигнованиеләре торган Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына һәм Байконур шәһәре бюджетына максатчан билгеләнешкә ия башка бюджетара трансфертларны бирү кагыйдәләрен раслау турында» 2022 елның 1 февралендәге 85 номерлы карары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Бу каракарга теркәлгән 2022 елда яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы, амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтелүче пациентларны дәвалау өчен дару препаратлары сатып алу чараларын финанслар белән тәэмин иткәндә барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым

йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган максатчан билгеләнешкә ия башка бюджетара трансферттан файдалану тәртибен расларга.

2. Бу карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Сәламәтлек саклау, спорт һәм сәламәт яшәү рәвешен формалаштыру мәсьәләләре идарәсенә йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2022 ел, 7 март, 205 нче
карары белән расланды

2022 елда яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы, амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтелүче пациентларны дәвалау өчен дару препаратлары сатып алу чараларын финанслар белән тәэмин иткәндә барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган максатчан билгеләнешкә ия башка бюджетара трансферттан файдалану тәртибе

1. Бу Тәртип 2022 елда яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы, амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтелүче пациентларны дәвалау өчен дару препаратлары сатып алу чараларын финанслар белән тәэмин иткәндә барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган максатчан билгеләнешкә ия башка бюджетара трансфертны (алга таба – башка бюджетара трансферт) сарыф итү механизмын билгели.

2. Башка бюджетара трансферт акчасы яңа коронавирус йогышлы авыруы (COVID-19) белән авыручы, амбулатор шартларда медицина ярдәме күрсәтелүче пациентларны (алга таба – яңа коронавирус йогышлы авыруы белән авыручы пациентлар) дәвалау өчен дару препаратлары сатып алу чараларын финанслар белән тәэмин иткәндә барлыкка килә торган Татарстан Республикасы чыгым йөкләмәләрен финанслашуга җибәрелә.

3. Татарстан Республикасы бюджеты акчасы белән баш эш итүче – Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы.

4. Акчаны тоту Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан Татарстан Республикасы Финанс министрлыгында ачылган шәхси счет аша гамәлгә ашырыла.

5. Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы, финанслауның иң чик күләмнәре Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы тарафыннан җиткерелгәннән соң, финанслауның иң чик күләмнәрен 2022 елга Татарстан Республикасы бюджетында каралган бюджет ассигнованиеләре күләмнәре һәм расланган бюджет йөкләмәләре лимитлары чикләрендә Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгына җиткерә.

6. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы:

дәүләт ихтыяҗларын һәм муниципаль ихтыяҗларны тәэмин итү өчен товарлар, эшләр, хезмәт күрсәтүләрне сатып алу өлкәсендә контракт системасы турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә, яңа коронавирус йогышлы авыруы белән авыручы пациентларны дәвалауга дару препаратлары сатып алу өчен казначылык тарафыннан булышлык ителү турында шартлары булган дәүләт контрактларын (шартнамәләр) төзи;

дәүләт контрактлары (шартнамәләр) шартларына туры китереп, яңа коронавирус йогышлы авыруы белән авыручы пациентларны дәвалау өчен дару препаратлары сатып алуга дәүләт контрактлары (шартнамәләр) төзегән оешмаларга акча күчерә;

яңа коронавирус йогышлы авыруы белән авыручы пациентларны дару препаратлары белән тәэмин итү тәртибен билгели.

7. Татарстан Республикасы Сәламәтлек саклау министрлыгы «Электрон бюджет» иҗтимагый финанслар белән идарә итүнең интеграцияләнгән мәгълүмат системасында Россия Федерациясе Сәламәтлек саклау министрлыгы һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты арасында башка бюджетара трансферт бирү турында килешү белән билгеләнгән формада һәм срокларда түбәндәгеләрне урнаштыра:

а) финанслашу өчен башка бюджетара трансферт бирелә торган Татарстан Республикасы бюджеты чыгымнары турында хисап;

б) башка бюджетара трансферт бирү нәтиҗәсе мәгънәсенә ирешү турында хисап.

8. Башка бюджетара трансферт акчасыннан максатчан файдаланылмау Россия Федерациясе бюджет законнары нигезендә җаваплылыкка тарта.

9. Агымдагы финанс елының 1 гыйнварына башка бюджетара трансфертның файдаланылмый калган өлеше Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән таләпләр нигезендә федераль бюджетка кире кайтарылырга тиеш.

___